| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**29.12.2023**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 4242**

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган һәм (яисә) гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектларын теркәү регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларында яңа инвестиция проектларына ярдәм итү системасын («Региональ инвестиция стандарты») гамәлгә кертүне исәпкә алып, муниципаль берәмлекләр тарафыннан инвестиция проектлары буенча системалы эшне оештыру буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында»гы 2023 елның 26 сентябрендәге 672 номерлы боерыгына кушымтаның 12 пункты нигезендә, шулай ук Зеленодольск муниципаль районының уңай инвестиция климатын тәэмин итү, инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру, инвестиция проектларын оештыру һәм Зеленодольск муниципаль районы икътисадына инвестиция ресурсларын җәлеп итү эшчәнлеген координацияләүне көчәйтү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган һәм (яисә) гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестицион проектлар регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (https://zelenodolsk.tatarstan.ru)урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.С. Бауэрга йөкләргә.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2023
елның 29 декабрендәге 4242
номерлы карарына
кушымта

# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН ҺӘМ (ЯКИ) ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ПЛАНЛАШТЫРЫЛА ТОРГАН ИНВЕСТИЦИЯ ПРОЕКТЛАРЫН ТЕРКӘҮ РЕГЛАМЕНТЫ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган һәм (яисә) гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектлар регламенты (алга таба - Регламент) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - ЗМР Башкарма комитеты) тарафыннан Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла һәм (яисә) гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектларын карау һәм оештыру тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Регламент инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда оештыру ягыннан ярдәм күрсәтү буенча гамәлләрнең срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

1.3. Әлеге Регламент максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1.3.1. Инвестор - Зеленодольск муниципаль районына инвестицияләр рәвешендә үзенекен, заем яисә җәлеп ителгән акчаларны кертүне гамәлгә ашыручы һәм аларны максатчан файдалануны тәэмин итүче инвестиция эшчәнлеге субъекты.

1.3.2. Инвестиция проекты инициаторы - Зеленодольск муниципаль районы территориясендә инвестицион проектны гамәлгә ашыруга тәкъдим итүче физик яки юридик зат.

1.3.3. Инвестиция проекты - инвестицияләрне гамәлгә ашыруның икътисадый максатка ярашлылыгын, күләмен һәм срокларын, шул исәптән законнар нигезендә эшләнгән кирәкле проект-смета документациясен нигезләү, шулай ук инвестицияләрне, шул исәптән экспортка юнәлтелгән инвестицияләрне, җитештерелә торган продукциянең, товарларның, дөнья базарларында хезмәт күрсәтүләрнең конкурентлыкка сәләтен үстерү (бизнес-план) буенча практик гамәлләр тасвирламасы.

1.3.4. Инвестиция мәйданчыгы - потенциаль рәвештә инвестиция проектын гамәлгә ашыру урыны булган җир кишәрлеге (җитештерү урыны).

1.3.5. Инвестиция проекты резюмесы - әлеге Регламентка кушымта нигезендә форма буенча инициатор тарафыннан тәкъдим ителә торган инвестиция проекты турында кыскача мәгълүмат.

1.3.6. Инвестиция проектларының муниципаль реестры - Зеленодольск муниципаль районының инвестиция проектлары турында мәгълүматны саклауны күздә тоткан Зеленодольск муниципаль районының инвестиция проектларын исәпкә алуның мәгълүмати системасы.

1.3.7. Инвестиция проектын теркәү - инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда инициаторларга мәгълүмати, консультация һәм оештыру ярдәме күрсәтү буенча Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм Зеленодольск муниципаль районы учреждениеләренең эзлекле гамәлләр комплексы.

Инвестицион проектларны теркәү түбәндәге принципларга нигезләнә:

- кабул ителә торган карарларның объективлыгы һәм икътисадый нигезләнгән

булуы;

- дәүләт, хезмәт яисә коммерция серенә карата Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматның барлык инвесторлар өчен ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы;

- инвесторларның тигез хокуклылыгы;

- кабул ителгән карарларны үтәүнең мәҗбүрилеге, инвесторлар хокукларының үзгәрешсез булуы;

- гавами һәм шәхси мәнфәгатьләрнең тигез булуы.

1.3.8. Вәкаләтле орган - «Зелёный Дол» инвестиция үзәге» Зеленодольск муниципаль районы автоном учреждениесе. Вәкаләтле орган инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны контрольдә тота.

1.3.9. Инвестиция советы - Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының Карары нигезендә эш итүче һәм Зеленодольск муниципаль районы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыруның максатчанлыгы турында рекомендация бирү хокукына ия булган, шулай ук проектның кураторын билгеләүче Зеленодольск муниципаль районының коллегиаль органы.

1.3.10. Инвестиция проекты кураторы - Зеленодольск муниципаль районы Инвестиция советы Карары белән билгеләнгән инвестиция проектын теркәүче җаваплы зат.

1.3.11. «Бер тәрәзә» принцибы - Куратор тарафыннан инвестиция проектын теркәү һәм аны гамәлгә ашыруның барлык этапларында нәтиҗәле ведомствоара хезмәттәшлекне оештыру.

## 2. Инвесторларга һәм инвестиция проектларына куела торган төп таләпләр

2.1. Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру.

2.2. Инвестиция проектлары:

- Зеленодольск муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенең төп юнәлешләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелергә тиеш;

- Зеленодольск муниципаль районындагы экологик вәзгыятькә тискәре йогынты ясарга тиеш түгел.

## 3. Инвестиция проектларын теркәү формалары

3.1. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган һәм (яисә) гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектларын гамәлгә ашыру түбәндәге юллар белән башкарыла:

- инвестиция проектын гамәлгә ашыру процессында барлыкка килә торган мәсьәләләрне компетенция чикләрендә хәл итүгә юнәлдерелгән сөйләшүләр, очрашулар, киңәшмәләр, консультацияләр оештыру;

- инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган җир кишәрлекләре, кулланылмый торган җитештерү урыннары һәм аларны бирү тәртибе турында мәгълүмат белән тәэмин итү ;

- гамәлдәге законнар нигезендә күчемсез милек объектларын төзү өчен җир кишәрлегенә хокукларны теркәүне рәсмиләштерүдә консультатив ярдәм күрсәтү;

- җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның категориясен һәм төрен үзгәртүдә ярдәм күрсәтү;

- капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга проект документациясен килештерүдә, капиталь төзелеш объектын төзүгә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәт алуда ярдәм күрсәтү;

- инвестиция проектын гамәлгә ашыруда дәүләт һәм муниципаль ярдәмнең мөмкин булган рәвешләре турында мәгълүмат бирү;

- республика һәм Россия базарларының структурасы һәм сыйдырышлылыгы, инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле хезмәт, җитештерү һәм инфраструктура ресурсларының тупланусы турында мәгълүмат бирү;

- Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган һәм (яисә) гамәлгә ашырылу планлаштырыла торган инвестиция проектлары һәм тәкъдим ителә торган инвестиция мәйданчыклары турында «Интернет» челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районы сайтында (https://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат урнаштыру.

## 4. Инвесторлар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе һәм сроклары

4.1. Инвестиция проектын теркәүне башлау өчен нигез булып инвестор яки инвестиция проекты инициаторы (алга таба инициатор) белән беренчел сөйләшүләр үткәрү яки ЗМР Башкарма комитеты адресына килгән ирекле формада язмача гаризасы (электрон почта аша гариза) тора.

4.2. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

- инвестиция проекты резюмесы (Регламентка кушымта);

- инвестиция проектын гамәлгә ашыру графигы.

4.3. Гариза һәм документлар ЗМР Башкарма комитетына кергән көнне эш алып бару һәм электрон документ әйләнешенең автоматлаштырылган системасында теркәлә.

4.4. ЗМР Башкарма комитеты җитәкчесе Инвестиция советына чыгару өчен Вәкаләтле органга гариза һәм документлар тапшыра.

4.5. Вәкаләтле орган гариза тапшырылганнан соң, 5 эш көне эчендә, 4.2 пунктында күрсәтелгән документларның тулылыгын (комплектлылыгын) һәм дөрес тутырылуын тикшерә. Документларны тутыруга һәм аларның комплектлылыгына карата кисәтүләр булганда, Вәкаләтле орган инвесторга (инициаторга) кисәтүләрне бетерү буенча тәкъдимнәрне исәпкә алып, аларны эшләп бетерү өчен инвесторга (инициаторга) җибәрә.

4.6. Форма һәм эчтәлеге буенча тапшырылган документлар тәкъдимнәрнең 4.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килгән очракта, Вәкаләтле орган гаризаны тапшырган көннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча:

- инвесторга (инициаторга) аның гаризасын алу турында хәбәр итә һәм үзенең контактларын хәбәр итә;

- инвестордан (инициатордан) контактлы зат турында мәгълүмат соратып ала;

- инвесторга (инициаторга) Татарстан Республикасында инвестицион эшчәнлеккә дәүләт ярдәме күрсәтүнең мөмкин булган формалары, консультация алу мөмкинлеге турында хәбәр итә;

- инвесторга Инвестиция советын үткәрү көне һәм урыны турында хәбәр итә.

4.7. Инвестиция советы тәкъдим ителгән документларны карый һәм, әлеге инвестиция проектын район территориясендә гамәлгә ашыруның максатчанлыгы турында карар кабул ителгән очракта, проект кураторын билгели. Әлеге карар беркетмә йөкләмәләре белән рәсмиләштерелә.

4.8. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашыруның максатчанлыгы турында карар кабул ителгәннән соң инвестор (инициатор) белән Беркетмә имзаланырга мөмкин.

4.9. Куратор ЗМР Башкарма комитетының структур бүлекчәләре белән берлектә инвестицион мәйданчыклар, эчке һәм тышкы инженерлык, транспорт, социаль һәм башка инфраструктура объектлары һәм аларның куәтләре турында тәкъдимнәр әзерлиләр.

4.10. Инвестор (инициатор) инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында карар кабул иткәнче, Куратор эш режимында инвестор (инициатор) белән кирәкле өстәмә мәгълүмат бирү буенча үзара бәйләнеш алып бара.

4.11. Кирәк булганда, Куратор инвестиция проектын гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен дәүләт хакимияте органнарына вәкаләтләр кысаларында ЗМР Башкарма комитеты исеменнән язма мөрәҗәгатьләр әзерли.

4.12. Инвестиция мәйданчыгы инвестор булып сайланган очракта, Куратор Вәкаләтле органга әлеге инвестиция мәйданчыгын Инвестиция советына кертү турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итә.

4.13. Инвестор тарафыннан Зеленодольск муниципаль районы территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында карар кабул ителгән инвестиция проектлары муниципаль реестрга кертелергә тиеш.

4.14. Инвестиция проектларының муниципаль реестрын Вәкаләтле орган алып бара.

4.15. Инвестиция проектларының муниципаль реестры Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

## 5. «Бер тәрәзә» принцибы буенча теркәлә торган проектны гамәлгә ашыру барышын мониторинглау

5.1. "Бер тәрәзә" принцибы буенча теркәлә торган инвестиция проектын тормышка ашыру мониторингын гамәлгә ашыру максатларында Куратор түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- инвестордан проектны гамәлгә ашыру барышы һәм проект турында теләсә кайсы стадиядә өстәмә мәгълүмат алу, шул исәптән проектны финанслауның факттагы күләмнәрен, булдырылган эш урыннары санын һәм уртача айлык хезмәт хакын күрсәтеп, мәгълүмат алу;
- инвесторны муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше турында, аның инвестиция һәм кадрлар потенциалы турында мәгълүмат белән тәэмин итү

5.2. Куратор проектны гамәлгә ашыру барышы турында инвесторга мәгълүмат алынган көннән алып биш эш көне эчендә аны Вәкаләтле органга җибәрә.

Регламентка кушымта

**Инвестиция проектының резюме формасы**

1. Инвестиция проекты исеме: ______________________________
2. Инвестор яисә инвестиция проекты инициаторы турында мәгълүмат:

| **Инвестиция проекты характеристикасы** | |
|---|---|
| Инвестиция проектының бизнес-идеясе (максаты) | |
| Инвестиция проекты гамәлгә ашыру барышында барлыкка килә торган оешма, производство керә торган икътисад тармагы | |
| Проектны урнаштыру (гамәлгә ашыру) урыны (шәһәр, җирлек, район) | |
| Инвестиция проектын гамәлгә ашыру формасы (яңа төзелеш, үзгәртеп кору, киңәйтү, реконструкция) | |
| Проектны чимал (материаллар) белән тәэмин итү | |
| Планлаштырылган продукция (хезмәт күрсәтүләр) | |
| Планлаштырылган җитештерүнең куәте | |
| Кулланучылар базарын тасвирлау | |
| Проектка әзерлек дәрәҗәсе һәм экспертиза | |
| Кирәкле инфраструктура (ресурслардан файдалану күләмен күрсәтеп) | |
| Проектны финанс бәяләү | |
| Проектның гомуми бәясе (млн. сум), шул исәптән:<br>- инвестицияләнә торган акчалары;<br>- сораган инвестицияләр | |
| Проект нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре | |
| Инвестиция проектын гамәлгә ашыру срогы (объектны гамәлгә кертү) | |
| Проектның үз-үзен аклау чоры (ел, ай.) | |
| Проектның рентабельлеге | |
| Төзелә торган эш урыннары саны, кеше. | |
| Проект буенча уртача хезмәт хакы (мең сум) | |

| База техник параметрлары | | | |
|---|---|---|---|
| № | Сорау | Җавап | Үлчәү берәмлеге |
| 1 | Җир кишәрлегенең мәйданы | | га |
| | җитештерү өчен мәйдан | | м2 |
| | чимал өчен склад бүлмәләренең мәйданы | | м2 |
| | әзер продукция өчен склад биналарының мәйданы | | м2 |
| | АБК мәйданы | | м2 |
| | җир кишәрлегенә өстәмә таләпләр | | |
| 2 | Бинаның биеклеге | | м |
| 3 | Идәнгә йөкләмә | | тонна/м2 |
| 4 | сыек/каты химик калдыклар булу | | |
| 5 | Электроэнергия (билгеләнгән куәт) | | МВт |
| 6 | Су | | м3/сут |
| 7 | Газ | | млн. м3/ел |
| | югары/түбән басым | | бар |
| | нинди ихтыяҗларга (биналарны җылытуга, технологик ихтыяҗларга) | | |
| 8 | Тимер юлга ихтыяҗ | | |
| 9 | Җылылык белән тәэмин итү | | Гкал/сәг |
| 10 | Техник су | | м3/сут |
| 11 | Хуҗалык-көнкүреш канализациясе | | м3/сут |
| 12 | Сәнәгать суларын агызу | | м3/сут |
| 13 | Локаль чистартулар | | |
| 14 | Санитар-саклау зонасы | | |